| | |
|---|---|
| СОВЕТ НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ЗАРЕЧЕНСК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2020 нчы ел Яңа Зареченск авылы № 155

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Советы карарына үзгәрешләр кертү турында
үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең
сайланулы вазыйфаи затларының,
Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләренең
хезмәт өчен түләү чыгымнарын
формалаштыру нормативлары турында
(2018 елның 14 маендагы 68 номерлы, 2018 елның
18 октябрендәге 84 номерлы,
2018 елның 20 ноябрендәге 91 номерлы үзгәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районы Яна Зареченск авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 апрелендәге 65 номерлы "Татарстан

Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карарына (2018 елның 14 маендагы 68 номерлы, 2018 елның 18 октябрендәге 84 номерлы, 20.11.2018 елдагы 91 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының бер тапкыр күләменә исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11498 сум тәшкил итә..».

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе С.Н. Багижева